МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.04.2023 Казан ш № 294

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торак урыннарга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидияләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 635 номерлы боерыгы белән расланган Торак урыннарга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидияләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торак урыннарга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидияләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 635 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 31.10.2016 №612, 08.06.2017 №349, 01.06.2018 №426, 18.09.2018 №860, 23.04.2019 №297, 14.11.2019 №1021, 10.02.2020 №84, 08.06.2020 №400, 04.09.2020 №609, 21.05.2021 №331, 01.10.2021 №711 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Торак урыннарга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидияләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2023 елның 18 апрелендәге 294 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торак урыннарга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидияләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 635 номерлы боерыгы белән расланган Торак урыннарга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидияләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.»;

1.5.1 - 1.7 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы

Торак урыннарга һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия (алга таба – субсидия) бирү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең) исеме

2.2.1. Мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Үзәк бүлекчәсе йөзендә «Республикасы матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Үзәк, Үзәк бүлекчәсе).

2.2.2. Күпфункцияле үзәк (алга таба – КФҮ) аша дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү КФҮ гамәлгә ашырылмый.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында карар тора.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасында теркәлә.

2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

электрон документ формасында электрон почта һәм (яки) мөрәҗәгать итүченең Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталындагы (алга таба – Бердәм портал) (http://www.gosuslugi.ru/) һәм «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасындагы (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы) (http://uslugi.tatarstan.ru/) шәхси кабинетына җибәреп.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында хәбәр телефонга смс-хәбәр итеп җибәрелергә мөмкин.

2.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

2.3.5. Субсидия бирү турында карар реквизитлары:

субсидия бирү турында карар кабул иткән органның исеме;

документның исеме;

карар кабул итү номеры һәм датасы;

мөрәҗәгать итүченең (вәкил, опекун, ата-ана, попечитель) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

мөрәҗәгать итүченең теркәлү адресы;

мөрәҗәгать итүченең телефоны;

мөрәҗәгать итүченең электрон почтасы;

гариза номеры;

гаризаны теркәү көне;

субсидия бирү турында карар кабул иткән органның вәкаләтле хезмәткәре вазыйфасы;

субсидия бирү турында карар кабул иткән органның вәкаләтле хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

субсидия бирү турында карар кабул иткән органның вәкаләтле хезмәткәренең электрон имзасы турында мәгълүмат.

Субсидия бирүдән баш тарту турында карар реквизитлары:

субсидия бирү турында карар кабул иткән органның исеме;

документның исеме;

карар кабул итү номеры һәм датасы;

мөрәҗәгать итүченең (вәкил, опекун, ата-ана, попечитель) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

мөрәҗәгать итүченең теркәлү адресы;

мөрәҗәгать итүченең телефоны;

мөрәҗәгать итүченең электрон почтасы;

гариза номеры;

гаризаны теркәү көне;

субсидия бирү турында карар кабул иткән органның вәкаләтле хезмәткәре вазыйфасы;

субсидия бирү турында карар кабул иткән органның вәкаләтле хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

субсидия бирү турында карар кабул иткән органның вәкаләтле хезмәткәренең электрон имзасы турында мәгълүмат.

## 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең срогы

2.4.1. Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте Үзәк бүлекчәсе тарафыннан гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 10 календарь көн эчендә күрсәтелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм гариза почта аша җибәрелгән булса яисә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән Интернет челтәре (алга таба – Интернет челтәре) аша җибәрелгән булса, дәүләт хезмәте Үзәк бүлекчәсе тарафыннан гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән башлап 10 эш көне эчендә күрсәтелә.

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинет аша бирелгән очракта, дәүләт хезмәте Үзәк бүлекчәсе тарафыннан гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетта чагылдырыла торган «Документлар тикшерү» статусы бирелгән көннән башлап 10 эш көне эчендә күрсәтелә.

2.4.2. Әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән барлык документларны яки аларның бер өлешен электрон формада тапшырмаган очракта, гариза яки документларны электрон документ (документлар пакеты) рәвешендә алган көннән алып 10 көн узгач, дәүләт хезмәте күрсәтү әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында каралган барлык документларны электрон формада тапшырганчыга кадәр, әмма бер айдан артык булмаган вакытка туктатыла.

Бу очракта мөрәҗәгать итүче 2.6.1 пунктында күрсәтелгән барлык документларны тапшырган көн гариза бирү көне дип санала.

2.4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында карар имзаланган көннән алып бер календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүчегә шәхсән тапшырган очракта, субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында карар күчермәсе мөрәҗәгать итүчегә ул мөрәҗәгать иткән көндә тапшырыла.

## 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи

затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырыла торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар:

барлык гаилә әгъзаларын һәм туганлык дәрәҗәсен, почта адресын яисә кредит оешмасына социаль түләүләрне алу өчен федераль законнар нигезендә ачылган счетның реквизитларын күрсәтеп, (Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә – әлеге пункт таләпләре нигезендә имзаланган) гариза (әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә кәгазь чыганактагы документ рәвешендә; электрон рәвештә (Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Бердәм порталда интерактив форманы тутыру юлы белән, нинди дә булса башка формада гариза бирү зарурлыгыннан тыш);

мөрәҗәгать итүченең даими яшәү урыны буенча үзе теркәлгән торак урынга хуҗа булу һәм аннан файдалануының хокукый нигезләрен раслый торган документлар турында белешмәләр, әгәр мөрәҗәгать итүче найм килешүе буенча торак урынны шәхси торак фондында яллап торучы, торак, торак-төзелеш кооперативы яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы әгъзасы булып торса. Контракт буенча хәрби хезмәт уза торган, яшәү урыны буенча хәрби часть адресы буенча теркәлгән, ләкин хезмәт торак урыннары булмавы аркасында төзелгән найм (поднайм) килешүе шартларында торак урыннарда яши торган мөрәҗәгать итүче субсидия бирү турындагы гаризага шәхси торак фондында найм (поднайм) килешүе күчермәсен һәм хәрби частьтән хезмәт буенча торак урын бирү мөмкинлегенең булмавы турында белешмә терки;

мөрәҗәгать итүче белән аның белән бергә аның даими яшәү урыны буенча теркәлгән, ләкин гаризада аның гаилә әгъзалары сыйфатында күрсәтелмәгән гражданнар тарафыннан торак урынны ремонтлау һәм карап тоту һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен раслый торган документлар;

мөрәҗәгать итүченең чит ил гражданинына һәм аның гаилә әгъзаларының Россия Федерациясе белән субсидия бирүне күздә тотучы халыкара килешү төзелгән дәүләт гражданлыгына караганлыгын таныклый торган документларның күчермәләре.

мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының субсидия бирү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган керемнәре турында белешмәләр.

мөрәҗәгать итүчедә һәм аның гаилә әгъзаларында керемнәр булмаган очракта, мөрәҗәгать итүче өстәмә рәвештә гражданнарның керемнәре булмавын раслаучы документларның күчермәләрен тапшыра, аларга түбәндәгеләр керә:

а) 23 яшькәчә булган, урта һөнәри белем бирүнең һәм югары белем бирүнең төп мәгариф программалары буенча белем бирү оешмаларында көндезге формада укучы гражданнар өчен, – стипендия булмавы турында белешмә;

б) гражданнарның эшкә урнашу мөмкинлеге булмаган яки чикләнгән затлар

категорияләренә каравын раслаучы документ, аларга түбәндәгеләр керә:

беренчел тикшерү һәм суд тикшерүе чорында сак астында тотылучы затлар;

дәвамлы стационар дәвалавында булган затлар (шундый дәвалау чорына);

билгеләнгән тәртиптә билгесез югалган яки үлгән дип игълан ителгән чорына кадәр эзләтүдә булган затлар;

өч яшенә җиткәнчегә кадәр бала караучы, 1,5 яшенә җиткәнче баланы карау буенча отпуск чорында ай саен түләнә торган пособие һәм хезмәт шартнамәсе шартларында хезмәт мөнәсәбәтләрендә торган һәм өч яшенә кадәр бала карау буенча отпускта торучы гражданнарга ай саен түләнә торган компенсация түләвен алмаучы аналар.

мөрәҗәгать итүче аның белән бергә даими яшәү урыны буенча яшәгән затларны аның гаилә әгъзалары итеп тану турында суд карары актын тапшырырга хокуклы, – мөрәҗәгать итүче белән даими яшәү урыны буенча аның белән бергә яшәгән затлар арасында бер гаиләнеке булу мәсьәләсендә аңлашылмаучанлыклар булган очракта.

Гражданнарның гаилә әгъзалары, югарыда күрсәтелгән документларга өстәмә рәвештә, әлеге гражданнарның китү сәбәбен, шулай ук әлеге гражданнар киткәнче тиешле торак урында даими яшәү фактын раслаучы документларны тапшыралар.

Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә тапшырыла, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге хезмәткәре тарафыннан таныклана.

мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать иткәндә, үзләренең шәхесен таныклый торган һәм мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итү вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.

Гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең шәхесен таныклаучы документтан белешмәләр Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада бердәм идентификация һәм аутентификация системасындагы (алга таба – БИАС) исәпкә алу язуын раслаганда тикшерелә.

Физик зат тарафыннан бирелгән, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен мөрәҗәгать итү хокукын раслаучы ышанычнамә нотариусның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән раслана.

Дәүләт хезмәтеннән файдалану буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкысының электрон формасы, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) (http://mtsz.tatar.ru)

урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлекчәсенә түбәндәге ысулларның берсе буенча тапшырыла (җибәрелә) ала:

шәхсән яисә почта аша кәгазьдә;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Бердәм порталда шәхси кабинет аша гариза формасын тутыру юлы белән Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша электрон формада;

гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән Интернет челтәре аша.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Гаризаны һәм кирәкле документларны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да җибәргән очракта, гариза һәм электрон документ формасындагы документларның күчермәләре «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланырга (расланган булырга) тиеш.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм кирәкле документларны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша җибәргән очракта, гаризаны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә БИАС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

2.6.2. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар (белешмәләр):

торак урынга (фатирга, торак йортка, фатирның яисә торак йортның бер өлешенә) милекчелек хокукын дәүләт теркәвенә алу турында. Рәсми мөрәҗәгать Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә җибәрелә;

тууны дәүләт теркәвенә алу турында. Рәсми мөрәҗәгать Федераль салым хезмәтенә җибәрелә;

өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында. Рәсми мөрәҗәгать Федераль салым хезмәтенә җибәрелә;

аерылышуны дәүләт теркәвенә алу турында. Рәсми мөрәҗәгать Федераль салым хезмәтенә җибәрелә;

балага опека билгеләнүе турында. Рәсми мөрәҗәгать җирле үзидарә органына җибәрелә;

баланы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турында. Рәсми мөрәҗәгать җирле үзидарә органына җибәрелә;

дәүләтнең яки муниципаль торак фондындагы торак урыннан файдалануның хокукый нигезләре булуы турында. Рәсми мөрәҗәгать җирле үзидарә органына җибәрелә;

яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлү исәбе турында. Рәсми мөрәҗәгать

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына җибәрелә;

мөрәҗәгать итүче белән аның даими яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына җибәрелә;

эшсезлек буенча пособие күләме, эшсез гражданнарга матди ярдәм һәм бүтәнчә түләүләр, шулай ук мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри белем алу һәм өстәмә һөнәри белем алу чорында гражданнарга түләнә торган стипендия һәм матди ярдәм, җәмәгать эшләрендә катнашучы эшсез гражданнарга һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ эшсез гражданнарга аларның вакытлы эшләрдә катнашуы чорында түләнә торган түләүләр, шулай ук вакытлы эшләрдә катнашу чорында 14 яшьтән 18 яшькәчә булган балигълык яшенә җитмәгән гражданнарга түләүләр турында; Рәсми мөрәҗәгать Бердәм дәүләт социаль тәэмин итү мәгълүмат системасына җибәрелә;

торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүләр турында. Рәсми мөрәҗәгать халыкка торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтүче оешмаларга җибәрелә;

мөрәҗәгать итүчедә торак урынга һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткүгә түләү буенча законлы көченә кергән суд акты белән расланган, соңгы өч елдан артмаган чорда барлыкка килгән, түләнмәгән бурычның булмавы турында. Рәсми мөрәҗәгать халыкка торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтүче оешмаларга җибәрелә;

торак урынга һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү буенча социаль ярдәм чаралары сыйфатында алына торган түләүләрнең күләме турында. Рәсми мөрәҗәгать Бердәм дәүләт социаль тәэмин итү мәгълүмат системасына җибәрелә;

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды тарафыннан гамәлгә ашырыла торган пенсияләр, компенсация түләүләре һәм пенсионерларны өстәмә айлык матди тәэмин итү күләме турында. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына җибәрелә;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан түләнә торган пенсия күләме турында. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы;

Россия Федерациясе Оборона министрлыгы тарафыннан түләнә торган пенсия күләме турында. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Оборона министрлыгына җибәрелә;

җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына җибәрелә;

вакытлыча эшкә яраксызлык буенча пособиеләр турында. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына җибәрелә;

йөклелек һәм бала табу буенча  социаль яклау органнары яисә Россия Федерациясе Социаль иминият фонды территориаль органнары тарафыннан түләнә торга нпособие күләме турында. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына җибәрелә;

йөклелекнең иртәнге срокларында медицина оешмасында исәпкә баскан хатын-кызга айлык пособие күләме турында. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына җибәрелә;

бала карау буенча айлык пособие күләме турында. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына җибәрелә;

шәхси счетның иминият номеры турында. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына җибәрелә;

мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының субсидия бирү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган керемнәре турында. Рәсми мөрәҗәгать Федераль салым хезмәтенә җибәрелә;

мөрәҗәгать итүченең һәм (яки) аның гаилә әгъзаларының торак урынга һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү буенча ташлама, социаль ярдәм чаралары һәм компенсациягә хокукы турында. Рәсми мөрәҗәгать Бердәм дәүләт социаль тәэмин итү мәгълүмат системасына җибәрелә;

мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының Россия Федерациясе гражданлыгын раслаучы документлар турында – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына.

мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы;

күчермәләре Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган очракта, мөрәҗәгать итүче тарафыннан (мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта) төп документларның күрсәтелмәве;

63-ФЗ номерлы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнар таләпләренә туры китереп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә гариза һәм документлар тапшыру;

тапшырылган документларда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган чистартылган һәм текстны төзәткән урыннар булуы;

мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итмәве;

тапшырылган документларның хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү вакытына көчен югалтуы (шәхесне таныклый торган документ, мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклый торган документ, – хезмәт күрсәтүне сорап әлеге зат мөрәҗәгать иткән очракта).

документларда хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булуы;

63-ФЗ номерлы федераль законның 11 статьясында билгеләнгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартларының үтәлмәве;

гариза формасында мәҗбүри кырларны корректлы (дөрес, төгәл яки тулы) тутырмау;

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм башка документлар Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган, дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка туры китереп тапшырылган булсалар, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

Хезмәт күрсәтүне туктатып тору нигезләре булып түбәндәгеләр тора:

әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән барлык документларны яки бер өлешен электрон документ рәвешендә тапшырмау.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

законлы көченә кергән суд акты белән расланган ТКХ өчен түләнмәгән бурыч булуы;

мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының яшәгән урыны буенча Татарстан Республикасы территориясендә теркәлмәгән булуы;

субсидия алу хокукының булмавы;

барлык документларны тапшыру зарурлыгы турында хәбәр иткән көннән башлап бер айдан артмаган срокта әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән барлык документларны яки бер өлешен электрон формада тапшырмау;

мөрәҗәгать итүченең тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүматларны тапшыруы;

электрон формада тапшырылган документларда булган белешмәләрнең мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазь чыганакта тапшырылган документларга туры килмәве.

Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Министрлыкның рәсми сайтында бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.10.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

2.11.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза кирәкле барлык документлары белән гариза алынган көнне теркәлә.

2.11.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соңгы ял (бәйрәм) көне булып саналмаган эш көнендә, ә гариза эш көне тәмамланганнан соң алынган очракта, икенче эш көнендә теркәлә.

2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла, көтү заллары (бүлмәләре) мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителә, аларда Үзәк бүлекчәсенең урнашу урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турында мәгълүмат, шулай ук, тутыру үрнәкләрен күрсәтеп, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларның рәвешләре урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт

күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-ноктaлы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.12.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) Үзәк бүлекчәсе хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) Үзәк бүлекчәсе хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-ноктaлы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2.12.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

## 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу күрсәткечләре:

инвалидларга бүтән затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачау

итүче киртәләрне җиңүдә ярдәм күрсәтү;

бүлек биналарының җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;

кирәкле санда белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинет аша алу мөмкинлеге.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;

Үзәк бүлекчәсе белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы.

2.13.3. мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлеге белгечләре белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны:

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта, шул исәптән электрон почта аша җибәргәндә турыдан-туры хезмәттәшлек итү таләп ителми.

2.13.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлекчәсе белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керүенең вакыт озынлыгы 15 минуттан артмый.

2.13.5. КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү КФҮ гамәлгә ашырылмый.

2.13.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлык (http://mtsz.tatarstan.ru) сайтыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан алынырга мөмкин.

2.13.7. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында

2.14.1. КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү КФҮ гамәлгә ашырылмый.

2.14.2. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче

хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге 7.2 пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Бердәм портал, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Үзәк бүлекчәсе, Үзәк, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Бу очракта мөрәҗәгать итүче яки аның законлы вәкиле Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында БИАС системасында исәпкә алыну язуын раслау юлы белән авторизация уза, электрон рәвештә интерактив формадан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тутыра.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында тутырылган гариза, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон рәвешләрен теркәп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлекчәсенә җибәрелә. БИАС системасында авторизацияләнгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза мөрәҗәгать итүченең, гаризаны имзалау өчен вәкаләтле мөрәҗәгать итүче вәкиленең гади электрон имзасы белән имзаланган дип санала.

Гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелгән очракта, әлеге Регламентның 2.3 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә, мөрәҗәгать итүченең вәкиленә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинетка Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган электрон документ формасында җибәрелә.

2.14.3. Электрон документлар түбәндәге форматларда тапшырыла:

а) xml - формалаштырылган документлар өчен;

б) doc, docx, odt - формулалары булмаган, текстлы эчтәлектәге документлар өчен (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш);

в) xls, xlsx, ods - исәпләмәләре булган документлар өчен;

г) pdf, jpg, jpeg - формулаларны һәм (яки) график сурәтләрне дә үз эченә алган (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш), шулай ук график сурәтләре булган документларны да кертеп, текстлы эчтәлектәге документлар өчен.

Документның үз оригиналын сканер аша уздыру юлы белән электрон документны формалаштыру рөхсәт ителә (күчермәләрне куллану рөхсәт ителми), ул 300 - 500 dpi (масштаб 1:1) мөмкинлегендә документ оригиналы ориентациясен саклап гамәлгә ашырыла, түбәндәге режимнарны кулланып:

«каралы-аклы» (документта график сурәтләр һәм (яки) төсле текст булмаган очракта);

«соры төсмерләрдә» (документта төсле график сурәтләрдән аерыла торган график сурәтләр булган очракта);

«төсле» яки «төсне тулы дәрәҗәсендә тапшыру режимы» (документта төсле график сурәтләр яисә төсле текст булган очракта);

чын нөсхәдәге барлык аутентик билгеләрне, атап әйткәндә: затның график имзасын, мөһерне, бланк чатындагы штампны саклап;

файллар саны һәркайсында текстлы һәм (яки) графикалы мәгълүматлар булган документлар санына туры килергә тиеш.

Электрон документлар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

документны һәм документтагы битләр санын идентификацияләү мөмкинлеген;

өлешләргә, бүлекләргә, кисәкләргә (кискәчләргә) бүленгән документлар өчен эчтәлек буенча һәм (яки) текстта булган рәсемнәргә һәм таблицаларга күчү мөмкинлеген.

xls, xlsx яки ods форматларында тапшырылырга тиешле документлар аерым электрон документ рәвешендә формалаштырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрне Үзәк бүлекчәсенә кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язу) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Үзәк бүлекчәсе телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә Үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, мөрәҗәгать итүчегә система аша соралган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән, кабул итү датасын, вакытын һәм урынын.

Алдан язылган вакытта, мөрәҗәгать итүчегә үзе тарафыннан гаризада күрсәтелгән ысул белән, әгәр дә ул кабул итү өчен билгеләнгән вакыттан соң 15 минут узгач килмәсә, алдан язылуның гамәлдән чыгарылачагы турында хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша яки Үзәк бүлекчәсе телефоны буенча алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул

итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

2.14.4. Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла:

«Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасы;

«Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.»;

3 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары»;

3.4.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Үзәк бүлекчәсе белгече мәгълүматлар ала:

торак урынга (фатирга, торак йортка, фатирның яки торак йортның бер өлешенә) милекчелек хокукын дәүләт теркәвенә алу турында – Татарстан Республикасы буенча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсеннән;

Федераль салым хезмәтеннән тууны дәүләт теркәве турында;

гаилә коруны дәүләт теркәве турында – Федераль салым хезмәтеннән;

аерылышуны дәүләт теркәве турында – Федераль салым хезмәтеннән;

балага опека билгеләү турында – җирле үзидарә органыннан;

баланы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турында – җирле үзидарә органыннан;

дәүләтнең яки муниципаль торак фондындагы торак урыннан файдалануның хокукый нигезләре булуы турында – җирле үзидарә органыннан;

яшәү урыны һәм тору урыны буенча теркәлү исәбе турында - Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан;

даими яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итүче белән берлектә теркәлгән гражданнар турында – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан;

эшсезлек буенча пособие күләме, эшсез гражданнарга матди ярдәм һәм бүтәнчә түләүләр, шулай ук мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри белем алу һәм өстәмә һөнәри белем алу чорында гражданнарга түләнә торган стипендия һәм матди ярдәм, җәмәгать эшләрендә катнашучы эшсез гражданнарга һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ эшсез гражданнарга аларның вакытлы эшләрдә катнашуы чорында түләнә торган түләүләр, шулай ук вакытлы эшләрдә катнашу чорында 14 яшьтән 18 яшькәчә булган балигълык яшенә җитмәгән гражданнарга түләү турында – Бердәм социаль тәэмин итү дәүләт мәгълүмат системасыннан;

торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүләр турында – халыкка торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтүче оешмалардан;

мөрәҗәгать итүчедә торак урынга һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткүгә түләү буенча законлы көченә кергән суд акты белән расланган, соңгы өч елдан артмаган чорда барлыкка килгән, түләнмәгән бурычның булмавы турында – халыкка торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтүче оешмалардан;

торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм чаралары

сыйфатында алына торган түләүләрнең күләме турында – Бердәм социаль тәэмин итү дәүләт мәгълүмат системасыннан;

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды тарафыннан гамәлгә ашырыла торган пенсияләр, компенсация түләүләре һәм пенсионерларны өстәмә айлык матди тәэмин итү күләме турында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан түләнә торган пенсия күләме турында – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан;

Россия Федерациясе Оборона министрлыгыннан түләнә торган пенсия күләме турында – Россия Федерациясе Оборона министрлыгыннан;

җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондыннан;

вакытлыча эшкә сәләтсез булуга бәйле пособиеләр турында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондыннан;

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан түләнә торган йөклелек һәм бала табу буенча пособие күләме турында – Россия Федерациясе Социаль иминият фондының социаль яклау органнары яки территориаль органнарыннан;

йөклелекнең беренче срокларында медицина оешмасында исәпкә алынган хатын-кызга айлык пособие күләме турында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан;

баланы карау буенча айлык пособие күләме турында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан;

шәхси счетның иминият номеры турында – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондыннан;

мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының субсидия бирү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган керемнәре турында – Федераль салым хезмәтеннән;

мөрәҗәгать итүченең һәм (яки) аның гаилә әгъзаларының торак урынга һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү буенча ташлама, социаль ярдәм чаралары һәм компенсациягә хокукы турында – Бердәм социаль тәэмин итү дәүләт мәгълүмат системасыннан;

мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының Россия Федерациясе гражданлыгын раслаучы документлар турында – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан.

Әлеге органнарга ведомствоара мәгълүмат сорау турында рәсми мөрәҗәгать ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең региональ системаларын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гаризаны һәм гаризага теркәлгән документларны теркәгән көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: алынган мәгълүматлар.»;

3.4.2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Әлеге Регламентның 2.6.10 пунктында каралган белешмәләр ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек оештыруның киңәш итеүә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, Регламентның 2.6.2 пунктында каралган белешмәләр әлеге белешмәләрне үз эченә алган документлар белән эш итүче органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның 7.2 статьясының 3 өлеше нигезендә ведомствоара гаризаларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара рәсми мөрәҗәгать алынган көннән башлап биш эш көненнән артырга тиеш түгел.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр, сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки аларда булган белешмәләрне) алу.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.»;

3.5.1 пунктының беренче абзацында «һәм әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән мәгълүматларны» сүзләрен төшереп калдырырга:

4 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Үзәк бүлекчәсендәге белгечләрнең әлеге Регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтү буенча таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актларның нигезләмәләрен үтәвен һәм башкаруын көндәлек тикшереп тору Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләрен үтәүгә һәм башкаруга карата

тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан карарлар кабул ителүне көндәлек тикшереп торуны оештыру тәртибен һәм рәвешләрен Үзәк директоры билгели.

4.2. Әлеге Регламент үтәлешен контрольдә тоту әлеге контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле Министрлык аппараты бүлегенең һәм Татарстан Республикасы муниципаль районында һәм шәһәр округында Министрлыкның социаль яклау идарәсенең (бүлегенең) вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла, аларның вәкаләтләре Министрлыкның структур бүлекчәсе турындагы нигезләмәдә һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи регламентлары белән билгеләнә.

Белешмә телефоннар, дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

4.3. Әлеге Регламент үтәлешен контрольдә тоту дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләргә тикшерүләр үткәрүне, карарлар кабул итүне, җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.4. Әлеге Регламент үтәлешенә планнан тыш тикшерү уздыру турындагы карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) мөрәҗәгать итүчеләр Үзәкнең, Үзәк бүлекчәсенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавының) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.5. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, Үзәк хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.6. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Үзәк бүлекчәсе эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу мөмкинлеге һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында

мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карау юлы белән гамәлгә ашырыла.»;

5 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгатьне теркәү чоры бозылганда;»;

Регламентка 1 нче кушымтада:

2 пунктка 2 нче астөшермәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү турында гариза бирү аена кадәр 6 календарь ай эчендә алынган керемнәр күләме күрсәтелә;

3 пунктка 1 нче астөшермәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү турында гариза бирү аена кадәр 6 календарь ай эчендә алынган керемнәр күләме күрсәтелә;

Регламентка кушымтаны (белешмәлекне) үз көчен югалткан дип танырга.